СОВЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.01.2016 с. Старое Русское Маматкозино №5-30

Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 пункты, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советының 2015 елның 17 декабрендә кабул ителгән "Җирле референдум үткәрү инициативасы турында" № 4-27 карары нигезендә, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгының "Җирле референдум үткәрү инициативасы турында" 2015 елның 17 декабрендәге 2 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советы
-
-
карар итте:

1. 2016 елның 6 мартына Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:

- Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан халыкны су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү 126000 сумлык: 540 метр озынлыктагы су скважиналарын киртәләү, 3 данә озынлыктагы су скважиналарын буяу, су асты скважиналарын буяу, 60 метр озынлыктагы су асты электрүткәргечен алыштыру, 9 данә су башняларын ныгыту урыннарын алмаштыру, 1500 метр озынлыктагы торба үткәргечләрен өлешчә алмаштыру.

ӘЙЕ ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы
-
-
- В. Н. Матвеева

ЧАКЫРУ

Сезне 2016 елның 6 мартында, 08.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр, түбәндәге адрес буенча: Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Юл урамы, 1 йорт (Авыл клубы бинасы)

Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумда катнашырга чакырабыз:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:

- Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан халыкны су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү 126000 сумлык: 540 метр озынлыктагы су скважиналарын киртәләү, 3 данә озынлыктагы су скважиналарын буяу, су асты скважиналарын буяу, 60 метр озынлыктагы су асты электрүткәргечен алыштыру, 9 данә су башняларын ныгыту урыннарын алмаштыру, 1500 метр озынлыктагы торба үткәргечләрен өлешчә алмаштыру.